
иркәлиләр. Кинәт көчек күзен ача, сикерә, өрә башлый. Балалар урыннарына таба йөгерәләр, көчек аларны куа. Тотылган баланы «көчек» итеп билгеләргә мөмкин.
Уенга күрсәтмәләр
• Шигырьне әйтеп бетерми торып, балалар көчеккә кагылмыйлар.
• Балалар көчекне бераз сыйпаганнан соң гына, ул күзләрен ача, селкенә башлый.
• Уенны үзләштергәннән соң, көчекне балалар арасыннан сайларга мөмкин.
• Шигырьне алдан өйрәнергә кирәк

**Җитез балалар**

Балалар урындыкларда утырып торалар. Идәнгә куелган кәрзингә уртача зурлыктагы 5–6 туп салына. Балаларның бер өлеше (туп санына карап), утырган урыннарыннан торып, бер рәткә тезеләләр. Тђрбияче: «Бер, ике, өч», – ди дә кәрзиндәге тупларны тәгәрәтеп җибәрә. Балалар туплар артыннан йөгерәләр. Һәр бала бер тупны тотып, тәрбиячегә китереп бирә. Тәрбияче балаларны мактый. Туплар артыннан йөгергән балалар үз урыннарына килеп утыралар, ә алар урынына башка балалар чыга.

***Бергәләп өйрәник***



# *Куркынычсызлык кагыйдәләре*

## *Әти-әниләр өчен ярдәмлек*

## *(2-3 яшь)*

**Эндәшләр**

Песи-матур, нечкә бил,
Бала тирбәтергә кил.
Җылы җирдә яшәрсең,
Тәмле сөтләр эчәрсең,
Ап-ак күмәч ашарсың,
Ашап туйгач уйнарсың,
Уйнап туйгач йокларсың,
Бәлли-бәү! Бәлли-бәү!

Кояш, чык!
Болыт, кач!
Без уйнарбыз,
Җылыткач.

**Хайваннарны чакыру**

Чакырабыз кәҗәне:
— Кәҗ-кәҗ-кәҗ!
Кәҗ-кәҗ-кәҗ!
Чакырабыз маэмайны:
— Маһ-маһ-маһ!
Маһ-маһ-маһ!
Чакырабыз аткайны:
— Бах-бах-бах!
— Бах-бах-бах!

**Калач**

*(Татар халык әкияте)*

Карт белән карчык булган, ди. Ашарларына бетеп киткән, ди. Карчык чыга да бура төпләреннән онны себереп ала. Себереп ала да Калач пешерә. Калачны пешерә дә тәрәзә төбенә куя, караса, ул тәрәзә төбеннән тәгәрәп төшә дә китеп бара. Бара торгач, Калачка Бүре очрый. — Син кая барасың, Калач, — ди Бүре, — минем карыным ач, сине ашыйм, — ди. — Син мине ашама, — ди Калач, — мин сиңа җыр җырлыйм, — ди. — Йә, җырыңны җырла, — ди Бүре. Калач җырларга тотына: Әбиемнән дә качтым мин, Бабамнан да качтым мин, Синнән качам да качам, — ди. Шулай булгач, Бүре моны ашамый узып китә. Шулай барганда, Калачка Аю очрый. Аю да шулай ук әйтә: — Минем карыным ач, мин сине ашыйм, — ди. — Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм, — ди Калач. — Йә, җырыңны җырла, — ди Аю. Калач җырларга тотына: Әбиемнән дә качтым мин, Бабамнан да качтым мин, Бүредән дә качтым мин, Синнән качам да качам, — дип, тагын такмаклый бу. Аюга да бу җыр бик кызык булып күренә. Бу да ашамый узып китә. Тагын китә бу. Бара торгач, моңарга Төлке очрый. Төлке хәйләкәр була инде. — Кая барасың, Калач агай? — ди Төлке. — Барам әле, — ди Калач. — Мин сине ашыйм хәзер, — ди Төлке. 30 31 — Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлыйм, — ди Калач. — Йә, җырлап кара, — ди Төлке. Әбиемнән дә качтым мин, Бабамнан да качтым мин, Бүредән дә качтым мин, Аюдан да качтым мин, Синнән качам да качам, — ди Калач. — Ярар, алай булгач, чалкан ятып кара әле, — ди Төлке. Калач чалкан яткан иде, Төлке моны ашый да китә. Шуның белән әкият тә бетә.

*Хәрәкәтле уеннар*

**Йонлач көчек**

Балалар урындыкларда утырып торалар. Тәрбияче «йонлач көчек» була. Ул бүлмәнең бер читендә алга сузылган кулларына башын куеп утыра – «йоклый». Балалар, түбәндәге текстны әйтә-әйтә, әкрен генә аның янына киләләр:
Әнә ята йонлач кљчек,
Борынын сузган ул ничек?
Йоклаганга да ошый,
Әллә юриме мышный?
Уятыйк үзен – торсын!
Нәрсә булса да булсын!
Балалар, шигырьне әйтеп бетергәннән соң, көчекне сыйпыйлар,